күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

4 нче чыгарылыш
3 нче гыйнвар



Әкрен генә йомшак карлар ява,
Күңелләргә шатлык, моң салып.
Яңа елда бәхет, шатлык килсен
Кышкы бураннарга уралып!
Күңелләрдә шатлык ташып торсын,
Сагышларга урын калмасын!
Алда туар көннәр якты булсын!
Ходай кайгылардан сакласын.

Җир өстенә аклык-пакьлек алып килгән Яңа ел бәйрәме котлы булсын! Киләсе елның 365 көне дә бәхет-шатлык кына китерсен. Аткан таңнарның барысы да алсу булсын. Тормыш юлларында шатлыклы очрашулар, бәхетле елмаюлар, куанычлы мизгелләр күп булсын!

Яңа елда өмет капкалары
Бәхет теләп кенә ачылсын
Һәрбер йортның ишек, тәрәзенә
Ак канаты белән кагылсын!
Котлы булсын Яна ел!
Гел шатлыктан торсын ул,
Бәхетле һәм мул тормышка
Күрсәтсен ул яна юл.
Яна ел котлы булсын!

# Мәктәп яңалыклары

**Ноябрь-декабрь** айларында төрле фәннәр буенча олимпиадаларның муниципаль этабы булып узды. Укучыларыбыз әлеге олимпиадаларда бик теләп катнаштылар. Кайбер фән олимпиадаларының инде җиңүчеләре һәм призерлары билгеле.

Инглиз теленнән: 1.Чоудри Камилла 7г сыйныф (укыт. Габдрахманова Е.С.)
2.Халиков Тимур 7а сыйныф (укыт. Шамсутдинова А.Ш.)
3.Байбакова Лейсан 6е сыйныф (укыт.Гимадиева Д.Р.)

Математика: 1.Грабалова Оксана 6д сыйныф (укыт. Нигметзянова Р.Х.)
2.Демьянов Роман 6д сыйныф (укыт. Нигметзянова Р.Х.)
3.Сивков Роман 4а сыйныф (укыт. Сорокина Ю.В.)

Рус теле : 1.Грабалова Оксана 6д сыйныф (укыт. Подовалов В.В.)

ТИН: 1.Матвеев Александр 3а сыйныф (укыт. Исмагилова А.И.)
2.Классен Даниил 10б сыйныф (укыт. Галиахметов А.Х.)

Әдәбият : 1.Пигалева Алиса 10а сыйныф (укыт. Галеева А.Р.)

Бөтен Рәсәй “Яңа ел планетасы” бәйгесе җиңүчеләрен, 1А сыйныф укучылары һәм аларның сыйныф җитәкчесе Зарипова И.В.ны, чын күңелдән котлыйбыз.

Аларга киләчәктә дә уңышлар теләп калабыз!



“Иң дус сыйныф серләре” республика бәйгесенең зона этабы җиңүчеләре, 7В сыйныфын (кл. җитәкчесе: Загидуллина Л.Ә), 3 нче дәрәҗә дипломнары белән котлыйбыз. Афәрин!




26 нчы декабрьдә мәктәбебездә II чирек бетү уңаеннан тантаналы линейкалар булды. Олимпиадаларда, конкурсларда, конференцияләрдә җиңүчеләргә диплом һәм грамоталар тапшырылды.

Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Михайлова Гөлнара Миннегали кызы балаларга юл йөрү кагыйдәләре, әдәплелек кагыйдәләре, бозга керергә ярамаганлыгы турында искә төшерде.



27 нче декабрь көнне 1-4 сыйныфлар өчен “Капка янында Яңа ел “ тамашасы күрсәтелде.

Укучылар Кыш бабай, Кар кызы, Убырлы һәм башка геройлар белән очрашып, әкият дөньясында “йөзделәр”. Балалар чын күңелдән әкияти дөньяга сәяхәт иттеләр, тамашадан соң күңелле уеннарда катнашып, кызыклы бүләкләр һәм Кыш бабай күчтәнәчләре алдылар.



**2 нче бит**

# Яңа ел турында нәрсә беләбез? [кызыклы фактлар]

**Яңа ел** - һәркемнең иң яраткан һәм көтеп алган бәйрәмнәренең берсе. Әмма бу бәйрәм турында без күп беләбезме соң? Яңа ел турында иң кызыклы фактларны җыярга булдык. Яңа елны бәйрәм итә башлау безнең эрага кадәрге 3 меңьеллыкка - Месопотамиягә барып тоташа. Вавилон халкыннан иудейлар, аннары греклар аша бу вакыйга Көнбатыш Европага кадәр килеп җитә. Аннары инде Җир шарының башка илләренә тарала.



Яңа елны бәйрәм итү вакыты төрлечә булган. Аны язын да, җәй көне дә, көзен дә, без гадәтләнгәнчә кыш көне дә бәйрәм иткәннәр. Хәзерге вакытта исә күпчелек илләрдә Яңа елны 31 декабрьдән 1нче гыйнварга каршы төндә бәйрәм итәләр.

Чыршы бизәү турында беренче рәсми мәгълүматлар XVII гасырга карый. Тарихчылар сүзләренчә, Раштуа уңаеннан беренче чыршыларны Эльзаста бизи башлыйлар. Төсле кәгазьдән ясалган розалар, алмалар, печенье, шикәр кисәкләре һәм мишура беренче уенчыклар була

Беренче пыяла чыршы уенчыгы Тюренгиядә (Саксония) XVI гасырда ясала. Чыршы уенчыкларын күпләп җитештерү исә XIX гасырда гына башлана.

Санта-Клаус беренче тапкыр 1822 елда Америка Кушма Штатларында барлыкка килә.

1947 елга кадәр 1 гыйнвар гадәти эш көне була. Календарьга үзгәреш Югары Совет Президиумының 1947 елның 23 декабрендә басылып чыккан указы буенча кертелә. Шуңа да 1948 елны СССР халкы инде ял итеп каршы ала.







Күсе – көнчыгыш йолдызнамәсенең иң беренче җәнлеге. Һәм көнчыгышта ул акча җәнлеге дип санала, шуңа күрә Яңа 2020 ел – финанс кыенлыкларын хәл итү һәм булачак имин тормышка нигез салу өчен кулай вакыт.

Күсе елында башланган эшләр уңышлы булыр, ләкин Күсе артык тәвәккәлләрне яратмый. Шуңа күрә үз көчегезне артык бәяләп ташламагыз.

2020 ел узып баручы Дуңгыз елына караганда уңышлырак булырга вәгъдә итә. Күсе югары интеллектка һәм сиземләү көченә ия. Ул менә дигән стратег, шуңа күрә хәйләкәр җәнлек теләсә нинди кыенлыкларны уңышлы гына хәл итә.

Ел символы үз дигәненә гадел юл белән омтылучыларга ярдәм итәчәк. Максатларына намуссыз төстә омтылучыларны уңышсызлык сагалап торачак. Күсе – мәхәббәт һәм игътибар символы, 2020 елда яңа мөнәсәбәтләрне үзара ышанычка кору яхшы.

2020 ел сәламәтлек ягыннан да сөендерер. Экспертлар мөмкин кадәр активрак булырга, спорт белән шөгыльләнергә киңәш итә.

Күсе көнчыгыш календаренда яңа юл символы булып тора. Ләкин үзгәрешләрнең нинди булуы һәркемнең үзеннән тора.

Редколлегия: Мәхмүтова Мәдинә, Мәхмүтова Мәликә, Вәлиева Диләрә,Корчагина Яна, Хәсәнова Адилә, Мельникова Аделина
Җитәкчесе:А.Ф.Габдуллаҗанова